КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 август г.Казань № 580

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын тормышка ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм җәмәгатьчелек фикер алышуы үткәрү максатларында аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен мәгълүмати ресурска урнаштыру тәртибен (http://tatarstan.ru/regulation);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү турында нигезләмә.

2. Бу караның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкручы Р.К.Нигъмәтуллин